ПРОЕКТ

СОВЕТ НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯР БУЕ МОРКВАШЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ул. Красивая, д.40, с. Набережные Моркваши, 422594

Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Моркваши авылы, 422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

30.10.2020 с. Набережные Моркваши № 2-22

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының «Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә җир салымын билгеләү турында» 2005нче елның 17нче ноябрендә кабул ителгән 13нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31нче бүлегенә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының «Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә җир салымын билгеләү турында» 2005нче елның 17нче ноябрендә кабул ителгән 12нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2нче статьясындагы 2нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Торак фонды һәм торак - коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән шөгыльләнүче җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына керми торган җир кишәрлегенә хокукы өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) 0,3%;

1.2. Карарның 2нче статьясындагы 3нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук "Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2017нче елның 29нчы июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,3%;

1.3. Карарның 4нче статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Статья 4. Салым түләү тәртибе һәм сроклары.

Салым салым түләүчеләр - оешмалар тарафыннан узган салым чорыннан соң килүче елның 1нче мартыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш. Салым буенча аванс түләүләре салым түләүчеләр - оешмалар тарафыннан узган хисап чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш».

2. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының «Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә җир салымын билгеләү турында» карары текстын яңа редакциядә расларга (1нче кушымта).

3. Әлеге карар 2021нче елның 1нче гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Бу карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Яр буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге
башлыгы И.Х.Гаязов

Югары Ослан муниципаль районы Яр Буе Морквашы авыл җирлеге Советының 2020нче елның 30нчы октябреннән 2-22нче номерлы карарына

1нче кушымта

Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориядә җир салымын билгеләү турында

Статья 1. Гомуми нигезләмәләр.

Россия Федерациясе Салым кодексының 31нче бүлеге нигезендә әлеге карар нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле җир салымы (алга таба – салым) билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

Статья 2. Салым ставкалары.

Салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган авыл хуҗалыгы кулланылышы зоналары составындагы җирләргә карата 0,3 % ;

2. Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән шөгыльләнүче җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына керми торган җир кишәрлегенә хокукы өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) 0,3%;

3. Эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук "Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2017нче елның 29нчы июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,3% ;

4. Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата, оборонаны, куркынычсызлыкны һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,3%;

5. Башка җир кишәрлекләренә карата 1.5 %.

Статья 3. Хисап чоры.

Салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы танылa.

Статья 4. Салым түләү тәртибе һәм сроклары.

Салым салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан узган салым чорыннан соң килүче елның 1нче мартыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш. Салым буенча аванс түләүләре салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан узган хисап чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш».

Статья 5. Салым ташламалары

Салым салудан азат итү:

1. Муниципаль берәмлек башкарма хакимияте органнары, зиратлар һәм гражданнар күмелгән җир кишәрлекләренә карата;

2. Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм инвалидларның тол ирләре (тол хатыннары), 4 һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган физик затларның салым түләүчеләре;

3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләренә, су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу объектлары белән шөгыльләнүче җир кишәрлекләренә, гомуми кулланылыштагы мәйданнар, урамнар, юллар, парклар, аллеялар, яшел үсентеләр, һәйкәлләр, бәйрәм чаралары үткәрү урыннары, спорт объектлары һәм башка гомуми файдаланудагы объектлар билэп торган җир кишәрлекләренә карата муниципаль берәмлек башкарма хакимияте органнары.

Җирле бюджеттан финанслана торган бюджет учреждениеләре биләгән җир кишәрлекләренә карата салымның киметелгән ставкасын 0,6% куллану рәвешендә җир салымын түләү буенча ташламаны, әлеге карарның 2нче статьясындагы 1, 2, 3, 4нче пунктларында каралган җир кишәрлекләреннән тыш, бирергә.

1-3 категория гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата салымның киметелгән ставкасын 0,05 % куллану рәвешендә җир салымын түләү буенча ташламалар бирергә.

Бюджет учреждениеләре тарафыннан республика һәм федераль бюджетлардан финанслана торган җир кишәрлекләренә карата, әлеге карарның 2нче статьясындагы 1, 2, 3, 4нче пунктларында каралган җир кишәрлекләреннән тыш, салымның киметелгән ставкасын 1% куллану рәвешендә җир салымын түләү буенча ташлама бирергә.

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру кысаларында төзелә торган торак һәм объектлар төзелешенә бирелгән (сатып алынган) җир кишәрлекләренә карата салымның киметелгән ставкасын куллану рәвешендә җир салымын түләү буенча ташламалар бирергә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И. Х. Гаязов